| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>АЛЕКСАНДРОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>АЛЕКСАНДРОВКА<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Александровка авылы

2019 ел, 8 апрель №103

**Баулы муниципаль районы Александровка авыл җирлегеннең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Александровка авыл җирлеге Уставы нигезендә, халык алдында тыңлаулары протоколы, Александровка авыл җирлегенең халык алдында тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы комиссия бәяләмәсе нигезендә карар Александровка авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Баулы муниципаль районы Александровка авыл җирлегеннең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Советының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

- «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Александровка авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы таләпләренә туры китерү турында»гы 2017 елның 26 июньнән 38нче номерлы карары;

- «Баулы муниципаль районы Александровка авыл җирлегеннең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 23нче октябреннән 47нче номерлы карары;

- «Баулы муниципаль районы Александровка авыл җирлегеннең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында»гы 2018 елның 20нче мартыннан 55нче номерлы карары.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Александровка авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе И.Р. Вәлиев